ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2024 п.г.т. Алексеевское № 435

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү Тәртибен раслау турында» 2022 елның 19 апрелендәге 137 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, «Федераль әһәмияттәге шәһәр Мәскәүдә һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында (Татарстан) «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законга, «Субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган грантлар бирү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.03.2019 елгы 322 номерлы карарына туры китереп

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының ««Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү Тәртибен раслау турында» 2022 елның 19 апрелендәге 137 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.3 нче пунктның 5 нче абзацы. 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- продукция җитештерү яисә хезмәт күрсәтү өчен кирәкле комплектлау

детальләре һәм чимал өчен, аларны китерү буенча транспорт чыгымнарын да кертеп, түләү;».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының ««Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү Тәртибен раслау турында» 2022 елның 19 апрелендәге 137 номерлы карарының 3 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Һөнәри керемгә салым»махсус салым режимын кулланучы физик затларны сайлап алу буенча конкурс комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе**

| | |
|---|---|
| Леденцов О.Н. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |

**Комиссия секретаре**

| | |
|---|---|
| Сафонова Н.В. | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |

**Комиссия әгъзалары**

| | |
|---|---|
| Язынин Р.С. | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Мифтахова Е.М. | Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килештерү буенча) |
| Сафина Г.Т. | Алексеевск муниципаль районы эшкуарлар Советы Рәисе (килештерү буенча) |
| Макарихина Е.С. | Ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе, Алексеевск муниципаль районы Иҗтимагый Советы Рәисе урынбасары (килештерү буенча) |
| Юртаева Ю.В. | Алексеевск муниципаль районының «Центральный» ТИҮ рәисе (килештерү буенча) |
| Голубева О.М. | Алексеевск районында эшчәнлек алып баручы шәхси эшмәкәр (килештерү буенча)» |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына

http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**